**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

01.07. 2026 ел №2165

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджетларына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә һәм исәптән чыгаруга өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибе хакында нигезләмәне раслау турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 26 октябрендәге 3642 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 06 маендагы 393 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 10 октябрендәге 1360 номерлы РФ Хөкүмәте Карары һәм «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 13 июлендәге 177-ФЗ номерлы (2024 елның 29 октябренә үзгәрешләр белән) Федераль закон нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджетларына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә һәм исәптән чыгаруга өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибе хакында нигезләмәне раслау турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 26 октябрендәге 3642 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 пунктның «а» пунктчасында «хисаплылыктан өземтә» сүзләрен «белешмә» сүзенә алыштырырга;

1.2. 2 пунктның «б» пунктчасын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) «Бөлгенлек (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданның, шәхси эшмәкәрнең банкротлык процедурасы тәмамлану - күрсәтелгән Федераль закон нигезендә бюджетка түләү бурычын үтәүдән азат ителгән бюджетка түләүләр буенча бурыч өлешендә».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), рәсми сайтта (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Н. Маняпов